РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
СОВЕТ БЮРГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БОЕРГАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ                КАРАР

«22» декабрь 2020ел                № 2-7

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Боерган авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы һәм муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 февралендәге 68-1 номерлы карары белән расланган (12.02.2020 ел № 83-1, 20.10.2020 ел № 4-1, 23.11.2020 ел 1-7 номерлы карар редакциясендә), Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (алга таба текст буенча – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 25 бүлек:

25.4 пунктының 2 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«2) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе, шулай ук кирәк булганда муниципаль хезмәтнең стажын (2020 елның 1 гыйнварына кадәр чорлар өчен) һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 25.06.2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы статьясында күрсәтелгән башка документларның күчермәләре;».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

Буа муниципаль районы Боерган
авыл җирлеге башлыгы                И.В. Малышева